**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_11__» ____04_____ 2018 ел.** **№ ___76___**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 27 июлендәге 235 номерлы «2016-2020 елларга Азнакай муниципаль районында сәламәтлек саклауны үстерү» муниципаль программасы турында»гы карары белән расланган «2016-2020 елларга Азнакай муниципаль районында сәламәтлек саклауны үстерү» муниципаль программасының 4 нче ярдәмче программасына үзгәрешләр кертү турында (04.08.2016 № 242, 05.04.2017 №88, 30.11.2017 № 302 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасында алкоголь һәм спиртлы продукциянең әйләнеше өлкәсендәге вәзгыятьне тикшереп тору буенча 2018 елның 28 февралендәге беркетмәсен исәпкә алып, анда чаралар планнарына төзәтмәләр кертү һәм алкоголь продукциясен явызларча куллану һәм сәламәт яшәү рәвешен индикаторлар - ирешелгән нәтиҗәләрне бәяләүнең максатчан критерийлары белән профилактикалау программалары өстәргә кушылган, карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 27 июлендәге 235 номерлы «2016-2020 елларга Азнакай муниципаль районында сәламәтлек саклауны үстерү» муниципаль программасы турында»гы карары белән расланган «2016-2020 елларга Азнакай муниципаль районында сәламәтлек саклауны үстерү» муниципаль программасының 4 нче ярдәмче программасына (04.08.2016 № 242, 05.04.2017 №88, 30.11.2017 № 302 карарлар редакциясендә) «2016-2020 елларга Азнакай муниципаль районында алкоголь продукциясен явызларча куллану һәм алкоголизмны профилактикалау масштабларын киметү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары» дигән таблицалар өстәп, әлеге карарга кушымта нигезендә, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2016 елның 27 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләре буенча урынбасары Д.Р. Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль Башкарма комитеты карарына кушымта
«___»__________2018 №_________

**«2016-2020 елларга Азнакай муниципаль районында алкоголь продукциясен явызларча куллану һәм алкоголизмны профилактикалау» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары**

| Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның билгеләре | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2016 ел (төп) | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Наркологның исерткеч эчемлекләр куллану буенча табибында хисапта торучы гражданнар саны | 240 | 267 | 255 | 243 | 228 |
| Наркологлар табибы хисабыннан алынган гражданнар өлеше, табибта наркологта хисапта торучы гражданнарның гомуми саныннан % | 35 | 20 | 20 | 20 | 20 |
| Алкоголь белән агулану нәтиҗәсендә үлем очраклары, берәмлекләр саны | 3 | 4 | 3 | 3 | 2 |
| Исерек хәлдә кылынган җинаятьләр саны, гомумән алганда, тикшерелгән җинаятьләр, берәмлекләр | 199 | 171 | 168 | 165 | 160 |
| Физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче гражданнар саны, % | 42,7 | 47 | 49 | 50 | 50 |